**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА
СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ ЭЛМЭТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«01»апрель 2024 ел № 3

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 11 апрелендә Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Иске Әлмәт авылы, Октябрь урамы, 19 йорт адресы буенча Иске Әлмәт мәдәният йорты бинасында 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында яшәүче Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында үзара салым кертү һәм элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган карарларда гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 15 мартындагы 1 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар Җыенының 15.03.2024 ел, № 2 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан , Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан тыш, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны карап тоту, вак таш сатып алу, юл япмасы профилен үзгәртеп, юлларны ясауда хезмәт күрсәтү).

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдерлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба юл күтәрү өчен тыгыз нигез салу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен төзекләндерү);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов